**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 16 июнь № 408

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналының исеме үзгәрү белән бәйле Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 19 май, 356 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган 3 бүлек Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрендә 3.2.3 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыкларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 ел, 5 сентябрь, 524 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 ел, 18 апрель, 212 нче; 2015 ел, 29 сентябрь, 722 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы» сүзләренә алмаштырырга.

3. Массакүләм мәгълүмат чарасы – «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналын теркәүгә алганчы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының – Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару чыганагы булып «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы була.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков